МУНИЦИПАЛЬНОЕ
КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ЗЕМЕЛЬНО-
ИМУЩЕСТВЕННАЯ ПАЛАТА
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ҖИР-МӨЛКӘТ ПАЛАТАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ
КАЗНА
УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**

**КҮРСӘТМӘ**

18.03.2025 Алабуга шәһәре № 01-473

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасының муниципаль казна учреждениесенең «Муниципаль милектәге, вакыты чикләнмәгән дәүләт милкендәге, җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 25 октябрендәге 2108 номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә

1.Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Җир-мөлкәт палатасының муниципаль казна учреждениесенең 2017 елның 25 октябрендәге 2108 номерлы күрсәтмәсе белән расланган муниципаль милектәге, вакыты чикләнмәгән дәүләт милкендәге, җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.5.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5.6. Палата белгече, хәбәрнамә урнаштырылган көннән алып утыз көн эчендә башка гражданнарның аукционда катнашу нияте турында

гаризалары рәсми сайтына кергән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.».

2. Әлеге күрсәтмә рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Палата рәисе Г.С .Билалова